# «Телне тиз өйрәнергә теләсәгез»

(Ата – аналар өчен консультация)

Лев Минц унлап телдә укый һәм яза белә, иң мөһиме аның телләр өйрәнүдәге үз ысуллары бар. Ул күптән инде Мәскәү журналистлары арасында полиглот буларак танылган. Лев Минц махсус мәктәпне, яки тел өйрәнү югары уку йортын тәмамламаган кеше. Кызыксынып, һәр телне өйрәнү эшен үзе үзләштергән. Дүрт яшеннән аңа эвакуациядә Татарстанда яшәргә туры килә. Татар авылында тәүге мәртәбә үзенә чит – ят сүзләрне ишетә һәм аларның мәгънәсен белергә тырыша. Алтынчы классны тәмамлагач, әти – әнисе белән Латвиягә күчеп китә, бер елдан инде бөтенләй таныш булмаган телдә сөйләшүчеләр белән аралаша. Мәктәпкә укырга керә, инглиз телен өйрәнә, төрле телдәге сүзләрне чагыштырып карый. Өч елдан Литвада да шундый ук хәл кабатлана. Литва теле дәреслеге сатып ала, аның грамматикасы белән танышу күңеленә хуш килә, шуны гаять зур шатлык белән укый. Грамматиканы өйрәнергә, аны тоемларга, сиземли белергә кирәк, ди ул. Бераздан бу гаилә Эстониягә күчеп китә, андагы халык теленең венгер теленә охшаш, тугандаш булуына гаҗәпләнә.

Армиядә ул Удмуртиядә хезмәт итә. Бу халыкның теле белән кызыксына. Аның турыдын – туры командирлары – украиннар була. Университетта укыганда, бер чех егете белән дуслаша, чех теле үзенчәлекләрен өйрәнә. Минем өчен иң кыены болгар теле булды, ди ул. Шуңа күрә тел чарлау өчен базарларда еш булырга ярата, чөнки анда бик күп милләт вәкилләре белән сөйләшергә мөмкинлек бар. Минц башка милләт вәкилләренең телен өйрәнүдән, алар белән аралаша белүдән үзенә шатлык таба.

Тел өйрәнергә ниятләгән кешеләргә Минцның менә тагын шундый киңәшләрен белү файдалы булырдыр:

-барыннан да бигрәк эзлеклелек һәм тырышлык булсын, грамматиканы ныклы үзләштерергә, телнең логикасын, телдәге тормыш сулышын сиземли белергә кирәк;

-чит телдә сөйләшергә оялмаска;

-үземнең бер серем дә бар бугай, ди ул: теге яки бу телне өйрәнә башлаганда, үземне шул телдә сөйләшүче кеше, яки дустым, танышым итеп күз алдыма китерәм. Әгәр шундый дустыгыз булмаса, үзегезне берәр яраткан артистыгыз итеп күзаллагыз.

Әлбәттә, телләр белән кызыксыну, аларны өйрәнүдә ихтыяр көче дә кирәк.

Күп телләрне белүчеләр болай диләр: теге яки бу телне өйрәнергә теләсәгез, әйтәсе фикерегезне дә шул телдә әйтеп бирергә омтылыгыз.

Икенче шарт: бик нык кызыксынучан булыгыз, шул телне белүчеләр белән күбрәк аралашырга тырышыгыз.

Өченче шарт: күбрәк музыка тыңлагыз, ишетү сәләтегезне үстерегез. Ишетү-чит телне өйрәнүдә иң яхшы ярдәмче.

Телне өч төрле юл белән өйрәнергә мөмкин. Мәсәлән, укытучы әйбернең исемнәрен атый, ә бала сүзләрне истә калдырганчы кабатлый.

Икенче ысул-магнитофон ярдәмендә. Аны төгәл аңлатма биргән кулланма ярдәмендә тыңлагыз.

Иң киң таралган ысул – тизләтелгән метод. Ул грамматика, тел бүленешләрен өйрәтүне максат итеп куймый. Иң мөһиме – сөйләшергә мәҗбүр итү.

Ә хәзер чит тел өйрәнүчеләр белергә тиешле иң мөйһим ун кагыйдәне искә төшерик:

1. Өйрәнү даими булырга тиеш. Атнага бер тапкыр берничә сәгать укуга караганда, аз-азлап һәр көнне өйрәнүгә ни җитә.
2. Үзең белән һәрвакыт сүзлек, текстлар язылган куен дәфтәре йөрт.
3. Дәресләрнең формасын төрләндер: укы, аннан тыңла, грамматика өйрән, яз.
4. Бирелгән тексттагы сүзләрне өйрән.
5. Текст авыррак аңлашылса да, мөмкин кадәр күбрәк укырга тырышыгыз.
6. Булдыра алганчы ятла.
7. “Әйтергә кирәк”, “игътибарыгызны шуңа юнәлтәм”, “минемчә” кебек сүзләрне күбрәк өйрәнегез, алар алдагы фразаны әйтер алдыннан уйланырга мөмкинлек калдыралар.
8. Тел-ныгытма (крепость), шуны онытма. Шуңа аны төрле яктан яулап алырга тырышырга кирәк. Практика – уңышның нигезе. Кечкенә генә мөмкинлекне дә ычкындырмаска.
9. Хаталардан курыкмагыз. Хата ясамыйча гына өйрәнеп булмый. Артык кыюсызлык бу очракта ярдәм итми, үзеңә ышанудан зыян юк.
10. Буш вакытыгызны әрәм итмәгез. Шәһәр транспортында йөргәндә дә, көткәндә дә сүзләр ятлый торыгыз.

Бу кагыйдәләрне үтәгән һәркем полиглот була.